ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ***
***БУА ШӘҺӘР СОВЕТЫ***

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
***БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН***
***БУИНСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ***

# КАРАР
# РЕШЕНИЕ

24 июнь 2020 ел №4-58

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы
Буа шәһәр Советының «Җир салымы турында»
2019 елның 23 июлендәге 4-43 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Салым кодексының 31 нче бүлеге нигезләмәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының «Җир салымы турында» 2019 елның 23 июлендәге 4-43 номерлы карарын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Буа муниципаль районы Буа шәһәр Советы карар итте:

I. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Буа шәһәр Советының 2019 елның 23 июлендәге 4-43 номерлы карарына (25.02.202020 ел, № 1-53 карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 статьяның 1 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары белән җир кишәрлекләренә карата кадастр бәясенең 0,201%ы (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына керми торган җир кишәрлегенә хокукындагы өлештән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) (эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш);».

II. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

III. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча бастырылып чыгарылырга тиеш..

Буа муниципаль районының

Буа шәһәре башлыгы урынбасары С.А. Зайцева